ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.05.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1607**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган «Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 417 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021елның 27 октябрендәге «Тикшерү кәгазьләре формалары проектларын эшләүгә, эчтәлегенә, җәмәгатьчелек белән фикер алышу таләпләрен раслау, тикшерү кәгазьләре формаларын раслау, куллану, актуальләштерү, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очраклары турында» 1844 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган «Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 417 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. «Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015елның 28 апрелендәге 415 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021елның 16 апрелендәге 604 номерлы карары белән каралган, «Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасы» карарына 1,2 нче кушымталарда тикшерү кәгазе формасының беренче битенең өске почмагында урнашкан QR-кодны үз эченә ала.

1.2. Каррга 1,2 номерлы кушымтадагы 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гражданның яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры һәм (яисә) индивидуаль эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры, гражданны яисә индивидуаль

эшкуарны теркәү адресы, юридик затның исеме, салым түләүченең идентификация номеры һәм (яисә) төп дәүләт теркәве номеры, контрольдә тотыла торган затлар булып торучы юридик затның адресы (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре)».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы оставындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http:zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

1 нче кушымта

| |
|---|
| Контроль (күзәтчелек) чарасы турында белешмәләрне контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында урнаштыру (дата һәм исәпкә алу номеры), QR-код |

**ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ТИКШЕРҮ КӘГАЗЕ (КОНТРОЛЬ СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ)**

____________________________________________________________

(муниципаль контроль органы исеме)

ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬ

(муниципаль контроль төре)

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге),

1. Гражданның яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры һәм (яисә) индивидуаль эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры, гражданны яисә индивидуаль эшкуарны теркәү адресы, юридик затның исеме, салым түләүченең идентификация номеры һәм (яисә) төп дәүләт теркәве номеры, контрольдә тотыла торган затлар булып торучы юридик затның адресы (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре)

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

2. Тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны һәм (яисә) юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган җир кишәрлекләре

____________________________________________________________

3. Юридик затның, индивидуаль эшкуарның планлы тикшерүен үткәрү турында күрсәтмәнең реквизитлары: ________________________________________

(юридик затның, индивидуаль эшкуарның планлы тикшерүен үткәрү турында күрсәтмә номеры, датасы)

4. Тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүнең исәп номерын бердәм реестрда бирү датасы__________________________________________________

(тикшерүнең исәп номеры һәм бердәм тикшерүләр реестрында бирү датасы күрсәтелә)

5. Тикшерү кәгазенең формасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ________________________номеры карары белән расланды

6. Планлы тикшерү уздыручы һәм тикшерү кәгазен тутыручы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары ____________________________________________________________

7. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге, аларга җаваплар тикшерү предметын тәшкил итүче мәҗбүри таләпләрнең юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәлүе яисә үтәлмәве турында бер үк мәгънәдә таныклый:

| № т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар | Мәҗбүри таләпләр куелган структур берәмлекләрне күрсәтеп, норматив хокукый актларны реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Таләп кагылмый |
| 1 | Милек хокукында, башкача яисә мәҗбүри хокукта юридик зат яисә индивидуаль эшкуар биләгән территорияне, шулай ук биналарны, корылмаларны тоту һәм җыештыру, гамәлдәге законнарда һәм Җирлекне төзекләндерү кагыйдәләрендә каралган күләмдә гамәлгә ашырыламы? | 8.2 бүлеге “Территорияне җыештыру” “Зеленодольск шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре (алга таба - Төзекләндерү кагыйдәләре) | | | |
| 2 | Калдыкларны җыюга, алып китүгә, саклауга тиешле шартнамә төзү юлы белән каты коммуналь калдыклар белән эш итү тәэмин ителгәнме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.2.1.1 пункты | | | |
| 3 | Урналар һәм контейнерлар булу тәэмин ителгәнме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.2.1.3 пункты | | | |
| 4 | Урналарны һәм контейнерларны вакытында чистарту һәм дезинфекцияләү тәэмин ителәме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.2.8 пункты | | | |
| 5 | Тышкы мәгълүмат чаралары Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештерелгән паспорт нигезендә урнаштырыла һәм | Төзекләндерү кагыйдәләренең 2.9.1 пункты | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | файдаланыламы? | | | | |
| 6 | Тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы техник яктан төзек хәлдә һәм эстетик яктан каралган хәлдәме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 2.9.2 пункты | | | |
| 7 | Караңгы төшү белән көн саен яктылык рекламалары һәм вывескалар кабызыламы? Янган элементларга үз вакытында алмаштырыламы? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.9.7 пункты | | | |
| 8 | Балалар, спорт мәйданчыкларын, ял мәйданчыкларын төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә эксплуатацияләү тәэмин ителгәнме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 2.12 бүлек пункты | | | |
| 9 | Төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә корылма биналарының фасады бармы? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 11 бүлеге Биналар һәм корылмаларның фасадлары эчтәлеге | | | |
| 10 | Биналарда, корылмаларда йорт билгеләре, табличкалар ике дәүләт телендә урнаштырылганмы? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 2.11.3 пункты | | | |
| 11 | Инвалидларны һәм халыкның аз мобильле төркемнәрен (пандуслар, култыксалар һ.б.) йөртү өчен биналарның, корылмаларның керү юллары һәм җайланмалары җиһазланганмы? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 2.4.4 пункты | | | |
| 12 | Төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзелеш мәйданчыклары бармы? | “Җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү” бүлеге Төзекләндерү кагыйдәләре бүлеге | | | |
| 13 | Гамәлдәге яшел утыртмаларның тулы сакланышы, алар артыннан квалификацияле карау тәэмин ителгәнме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.6.2 пункты | | | |
| 14 | Кулланучылар, хезмәт күрсәтүче оешмалар, әлеге биналар (корылмалар, төзелешләр), түбәләрне һәм козырекларны вакытында кардан, боз һәм боз сөңгеләреннән чистарту, шулай ук территорияне кардан чистарту буенча чаралар күреләме? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.4.2. 8.4.2.1 пунктлары | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Җир эшләрен башкаруга рөхсәт (ордер) алынганмы? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.9.1.1.1 пункты | | | |
| 16 | Ордерда күрсәтелгән срокларда һәм тулы күләмдә төзекләндерү эшләре торгызылганмы? | Төзекләндерү кагыйдәләренең 8.9.7 пункты | | | |

"_" ________ 20__ ел
(тикшерү кәгазе тутыру датасы күрсәтелә)

| ____________________ | ____________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (тикшерү кәгазе тутыручы вазыйфаи зат) | (имза) | (тикшерү кәгазе тутыручы затның фамилиясе, атасының исеме (булса) |

2 нче кушымта

Контроль (күзәтчелек) чарасы турында белешмәләрне контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында урнаштыру (дата һәм исәпкә алу номеры), QR-код

# ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ТИКШЕРҮ КӘГАЗЕ (КОНТРОЛЬ СОРАУЛАР ИСЕМЛЕГЕ)

______________________________________________________

(муниципаль контроль органы исеме)

<u>ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬ</u>

(муниципаль контроль төре)

Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

1. Гражданның яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры һәм (яисә) индивидуаль эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры, гражданны яисә индивидуаль эшкуарны теркәү адресы, юридик затның исеме, салым түләүченең идентификация номеры һәм (яисә) төп дәүләт теркәве номеры, контрольдә тотыла торган затлар булып торучы юридик затның адресы (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре)

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

2. Тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны һәм (яисә) юридик зат, индивидуаль эшкуар файдалана торган җир кишәрлекләре

___________________________________________

3. Юридик затның, индивидуаль эшкуарның планлы тикшерүен үткәрү турында күрсәтмәнең реквизитлары :

______________________________________

(юридик затның, индивидуаль эшкуарның планлы тикшерүен үткәрү турында күрсәтмә номеры, датасы)

4. Тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүнең исәп номерын бердәм реестрда бирү датасы______________________________________________________________

(тикшерүнең исәп номеры һәм бердәм тикшерүләр реестрында бирү датасы күрсәтелә)

5. Тикшерү кәгазенең формасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының __________________________номеры карары белән расланды

Планлы тикшерү уздыручы һәм тикшерү кәгазен тутыручы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары

____________________________________________________________________________

7. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар исемлеге, аларга җаваплар тикшерү предметын тәшкил итүче мәҗбүри таләпләрнең юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәлүе яисә үтәлмәве турында бер үк мәгънәдә таныклый:

| № т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар | Мәҗбүри таләпләр куелган структур берәмлекләрне күрсәтеп, норматив хокукый актларны реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Таләп кагылмый |
| 1 | Милек хокукында, башкача яисә мәҗбүри хокукта юридик зат яисә индивидуаль эшкуар биләгән территорияне, шулай ук биналарны, корылмаларны тоту һәм җыештыру, гамәлдәге законнарда һәм Җирлекне төзекләндерү кагыйдәләрендә каралган күләмдә гамәлгә ашырыламы? | III бүлек «Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территорияләрен төзекләндерү, территорияләрне карап тотуны һәм җыештыруны оештыруга гомуми таләпләр» (алга таба - Кагыйдәләр) | | | |
| 2 | Калдыкларны җыюга, алып китүгә, саклауга тиешле шартнамә төзү юлы белән каты коммуналь калдыклар белән эш итү тәэмин ителгәнме? | V бүлек, “Кешеләр күпләп булу һәм ял итү урыннарын җыештыру, санитар яктан карап тоту һәм төзекләндерү” | | | |
| 3 | Урналар һәм контейнерлар булу тәэмин ителгәнме? | IV кисәк, “Җир кишәрлекләрен карап тоту” | | | |
| 4 | Урналарны һәм контейнерларны вакытында чистарту һәм дезинфекцияләү тәэмин ителәме? | IV кисәк, “Җир кишәрлекләрен карап тоту” | | | |
| 5 | Тышкы мәгълумат чаралары | VI бүлек, “Тышкы реклама | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештерелгән паспорт нигезендә урнаштырыла һәм файдаланыламы? | һәм мәгълүмат чаралары” | | | |
| 6 | Тышкы реклама һәм мәгълүмат чарасы техник яктан төзек хәлдә һәм эстетик яктан каралган хәлдәме? | VI бүлек, “Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары” | | | |
| 7 | Караңгы төшү белән көн саен яктылык рекламалары һәм вывескалар кабызыламы? Янган элементларга үз вакытында алмаштырыламы? | IV бүлек, “Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту, VI бүлек, “Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары” | | | |
| 8 | Балалар, спорт мәйданчыкларын, ял мәйданчыкларын төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә эксплуатацияләү тәэмин ителгәнме? | VI бүлек, “Мәйданчыклар”, “Балалар мәйданчыклары”, “Спорт мәйданчыклары”, “Ял мәйданчыклары” | | | |
| 9 | Төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә корылма биналарының фасады бармы? | IV бүлек, “Бина һәм корылмаларның фасадлары эчтәлеге” | | | |
| 10 | Биналарда, корылмаларда йорт билгеләре, табличкалар ике дәүләт телендә урнаштырылганмы? | IV бүлек, “Күрсәткечләр” | | | |
| 11 | Инвалидларны һәм халыкның аз мобильле төркемнәрен (пандуслар, култыксалар һ.б.) йөртү өчен биналарның, корылмаларның керү төркемнәре һәм җайланмалары җиһазланганмы? | IV бүлек,“ Керү юллары (кисешкән урын) | | | |
| 12 | Төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзелеш мәйданчыклары бармы? | IV бүлек“ Төзелеш эшләрен башкару урыннарын карап тоту” | | | |
| 13 | Гамәлдәге яшел утыртмаларның тулы саклanышы, аларны квалификацияле карау тәэмин ителгәнме? | IV бүлек, “Җир кишәрлекләрен карап тоту”<br><br>VI бүлек, “Яшелләндерү” | | | |
| 14 | Кулланучылар, хезмәт күрсәтүче оешмалар, әлеге биналар (корылмалар, төзелешләр), түбәләрне һәм козырекларны вакытында кардан, боз һәм боз сөңгеләреннән чистарту, | IV бүлек “Түбәләр” | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | шулай ук территорияне кардан чистарту буенча чаралар күреләме? | | | | |
| 15 | Җир эшләрен башкаруга рөхсәт (ордер) алынганмы? | IV бүлек“ Төзелеш эшләрен башкару урыннарын карап тоту” | | | |
| 16 | Ордерда күрсәтелгән срокларда һәм тулы күләмдә төзекләндерү эшләре торгызылганмы? | IV бүлек“ Төзелеш эшләрен башкару урыннарын карап тоту” | | | |

"____ " ________ 20__ ел
(тикшерү кәгазе тутыру датасы күрсәтелә)

_________________________ _____________ ________________________

(тикшерү кәгазе тутыручы вазыйфаи зат) (имза) (тикшерү кәгазе тутыручы затның фамилиясе, атасының исеме(булса)